ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

2017 елның 15 марты № 1

Ямбулат авылы

Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Ямбулат авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Карар бирәм:

1. Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авылы җирлегендә җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 2017 елның 27 марты, 10.00 сәгатьтә Ямбулат авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирелә торган адрес: Ямбулат авылы, Центральная урамы, 5 нче йорт, Ямбулат авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Е. Ю. Коноваловага (эш көннәрендә - 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр);

- Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү вакыты - 2017 елның 24 мартына кадәр ( тел 36-5-18).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Ямбулат авылы җирлеге башлыгы

М.Н. Әхмәтҗанов